ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӨҖЕМ АВЫЛ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422008, Таш-Чишмә авылы, М.Горький урамы, 29
Тел.: (8-84369) 3-50-10; факс: 3-50-10

УЗЮМСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422008, село Таш-Чишма, Ул. М.Горького, д.29
Тел.: (8-84369) 3-50-10; факс: 3-50-10

# КАРАР

“06” декабрь 2021 ел. № 24

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 28 февралендә 2 нче номерлы карары белән кабул ителгән “Муниципаль мәгълүмат системаларының эшчәнлеге һәм алардан файдалану тәртибе турында” гы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында.**

2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Өҗем авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 28 февралендә 2 нче номерлы карары белән кабул ителгән “Муниципаль мәгълүмат системаларының эшчәнлеге һәм алардан файдалану тәртибе турында” гы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. **3.9 пунктының 2 пунктчасында** "системалар" сүзләреннән соң "электрон мәйданчыклар" сүзләрен өстәргә;

1.2. **3.9 пунктының 1 пунктчасын** түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

“күрсәтелгән системаларның, электрон мәйданчыкларның бердәм мәгълүмат системасы белән үзара хезмәттәшлеге турында электрон документлар һәм мәгълүмат алмашу, ул әлеге Федераль законда каралган электрон документларны һәм мәгълүматны, шул исәптән региональ мәгълүмат системаларын кулланып, кул кую һәм урнаштыру белән бердәм мәгълүмати системага гарантияле тапшыруны тәэмин итә. Бердәм мәгълүмат системасында Электрон документлар һәм мәгълүмат урнаштыру өчен әлеге Федераль законда каралган срокларны исәпләү аларны бердәм мәгълүмат системасында урнаштырганнан бирле башлана";

1.3. **3.9 пунктта** "әлеге Нигезләмә" сүзләреннән соң "электрон мәйданчыклар" сүзләрен өстәргә;

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының http://atnya.tatarstan.ru/ рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru/ рәсми порталында игълан итәргә.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Өҗем авыл башкарма
комитеты җитәкчесе: Вәлиев А.Т.

УЗЮМСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ